«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары

2016 елның 3 октябре № 28

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Уставының 15 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советы карары:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге территориясендә түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:
«2016 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешенең 500 сум күләмендә үзара салым кертүенә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

- Балтач авылы (Кооператив ур., Школьная ур., Центральная ур.) юлларын ремонтлау ;
- чишмәләрне төзекләндерү
- зират коймаларын алыштыру

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:
- Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авылы, Мәктәп урамы, 1 нче йорт.
- Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авылы, Мәктәп урамы, 2.
шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Кама Тамагы муниципаль районының
Балтач авыл җирлеге башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Балтач
авыл җирлеге Советы Рәисе. Д.И.Мухамадуллин